**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Центральная, д. 3, с. Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Үзәк урамы, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 12 » май 2025 ел** **№ 10**

**Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 6 декабрендәге “Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләреннән файдалану турында” 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Хөкүмәтенең 2015 елның 28 августындагы “Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасы турында” 901 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы “Россия Федерациясе Һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләрен раслау турында” 138 номерлы карары (29.03.2024 редакциясе), РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән расланган РФдә янгынга каршы режим кагыйдәләре нигезендә, Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының **2024 елның 6 декабрендәге** “Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләреннән файдалану турында” 14 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктына түбәндәге абзац өстәргә:

«Биеклеге 50 метрдан артыграк булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә һава пространствосыннан файдалану Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның Бердәм системасы оператив органы (алга таба - Вәкаләтле орган) рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга, Яңа Кырлай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Яңа Кырлай авылы, Үзәк ур., 3 йорт, Өчили авылы, Тукай ур., 73 йорт.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге

башкарма комитеты җитәкчесе Г.Г.Сәфәров